


Бәйрәм 2000 елнын февралендә vк ботен донья буйлап билгеләп vтелә.
Телләрнен кvпторлелеге кешелекнен тотрыклы vсешенә ирешv очен аеруча моһим, чонки кvпмәдәниле җәмгыятьнен тату яшәве традицион белемнәрне һәм мәдәниятне тотрыклы нигездә тапшыручы һәм саклаучы туган телләрдән башка момкин тvгел.
Безнен илдә 193 халык яши, алар 277гә якын тел кулланыла, аларнын һәрберсе уникаль һәм кабатланмас. Россиядә укыту 24 телдә алып барыла, 81 тел уку программаларына аерым предмет буларак кертелгән.      Мордовиянен һәрбер мәдәният йортында, мәктәбендә туган рус, татар, мукшы, әрзә һәм башка телләргә багышлап чараларнын торлесен vткәрделәр. Шундыйларнын берсе «Фин-угор халыкларынын Идел буе vзәге» (Поволжский центр финно-угорских народов) оештырган милләтара фестивале иде.
Халыкара туган тел коне кысаларында Ләмберә районы Татар Тавла авылы халкы рухи-мәдәни vзәк хезмәткәрләре оештырган әдәби кичәдә катнаштылар. Татар Тавла топ гомуми белем бирv мәктәбе укучылары Самир Абдуллов, Аида Байгельдина, Салим Салиев «Фин-угор халыкларынын Идел буе vзәге» оештырган «Мордовия многонациональная» милләтара фестивале дипломнарына ия дә булдылар.
17-21 февраль коннәрендә Ромодан районы Алтар урта мәктәбендә Туган телләр атналыгы узган. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Венера Галләм кызы Конешева татар телендә vткәргән мавыктыргыч чарада укучыларны мәдәниятебез һәм тел мирасыбыз байлыгы белән таныштыра. Катнашучылар татар әдәбияты доньясына чумалар, кызыклы тарихлар һәм шигърият доньясы vрнәкләрен ишетәләр, шулай ук торле конкурсларда һәм викториналарда катнашалар. Сыйныфташларына телнен матурлыгын тоярга ярдәм итәләр һәм туган телебезнен матурлыгыннан ләззәтләнәләр.
Рузаевка районы Татар Пешлә клубында, Пушкин картасы буенча, «Туган тел илендә» дип аталган квиз узган. Чара барышында катнашучылар туган телне белvләрен генә тvгел, ә туган тел әдәбиятында, шулай ук традицияләрдә һәм мәдәниятта, татар мифологиясендә эрудициялелекләрен дә кvрсәткәннәр.
Кадошкино районы Большие Поляны топ мәктәбе укучылары «Халык зирәклеге» этно-викторинасында катнаштылар; анда балалар Россия халык-лары телләрендә танылган әйтемнәр әйтергә тырыштылар.
Шулай иттереп туган татар теленә багышланган чаралар vтvе дәвам итә.

Наилә НАСЫРОВА